**ГЛАВА
СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Урта Камышлы ав. **КАРАР**

**«10» ноябрь 2023 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Декабристлар урамындагы 1-38нче йортларда, К.Маркс тыкрыгы 1нче йортта, К. Маркс урамындагы 1-67нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын уздыру өчен Кече Камышлы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

4. «Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
- Урам утларын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина